КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 25 сентябрь г.Казань № 744

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем алучылар туклануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативлар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативларны;

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү базасында көндезге уку формасы буенча квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучылар туклануының көндезге рационы кыйммәтен;

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына олимпия резервы училищесында белем алучылар тукклануының спорт төренә һәм туклану продуктларының калориялелегенә бәйле булган тәүлеклек рационнан, энергия сарыф итү күләменнән чыгып билгеләнә торган көндезге рационы кыйммәтен.

2. Белем бирү оешмаларына ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, уку чорында ата-анасын икесен дә яки бердәнбер атасын-анасын югалткан затлар, инвалид балалар, I һәм II төркем инвалидлар, бала чактан инвалидлар булган студентларга, Чернобыль АЭСында һәлакәт һәм башка радиация

һәлакәтләре аркасында, Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган студентларга, хәрби хезмәт узган чорда алган хәрби имгәнү яки авыру аркасында инвалидлар һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары булган, шулай ук солдатлар, матрослар, сержантлар, старшиналар биләргә тиешле хәрби вазыйфаларда контракт буенча кимендә өч ел хезмәт иткән һәм хәрби хезмәттән «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 ел, 28 март, ФЗ-53 нче Федераль законның 51 статьясындагы 1 нче пунктның «б» – «г» пунктчаларында, 2 нче пунктның «а» пунктчасында һәм 3 нче пунктның «а» – «в» пунктчаларында күздә тотылган нигезләр буенча азат ителгән гражданнар арасындагы студентларга билгеләнә торган дәүләт социаль стипендияләр күләмнәрен билгеләгәндә әлеге карарның 1 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән тиешле нормативларга карата 1,5 арттыру коэффициентын куллануны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучылар туклануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативлар билгеләү турында» 2024 ел, 16 сентябрь, 795 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучылар туклануының көндезге рационы кыйммәтен һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативлар билгеләү турында» 2024 ел, 16 сентябрь, 795 нче карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативларга үзгәреш кертү хакында» 2025 ел, 12 апрель, 220 нче.

4. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 25 сентябрь, 744 нче карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен нормативлары

| Норматив исеме | Норматив күләме, бер укучыга аена сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2026 елның 1 гыйнварыннан | 2026 елның 1 сентябреннән | 2027 елның 1 сентябреннән | 2028 елның 1 сентябреннән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында фәнни-педагогик кадрлар әзерләү, ординатура, ассистентура-стажировка программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы аспирантларына, ординаторларына, ассистент-стажерларына дәүләт стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыру нормативы | 3 093 | 3 217 | 3 346 | 3 480 |
| югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыру нормативы | 2 263 | 2 354 | 2 448 | 2 546 |
| Һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге уку формасында урта звено белгечләрен | 824 | 857 | 891 | 927 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына; һөнәри белем бирү оешмаларының урта гомуми белем бирү базасында көндезге формада квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыру нормативы | | | | |
| Һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының төп гомуми белем бирү базасында көндезге уку формасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы студентларына дәүләт академик стипендиясен, дәүләт социаль стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыру нормативы | 590 | 614 | 639 | 665 |
| Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендәге дәүләт учреждениеләренең көндезге уку формасында фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программасы буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы аспирантларына дәүләт стипендиясен түләү өчен стипендия фондын формалаштыру нормативы | 8 384 | 8 719 | 9 068 | 9 431 |

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 25 сентябрь, 744 нче карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү базасында көндезге уку формасы буенча квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучылар туклануының көндезге рационы кыйммәте

| Күрсәткеч исеме | Күрсәткеч зурлыгы, бер укучыга көненә сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү базасында көндезге уку формасы буенча квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән белем алучы туклануының көндезге рационы кыйммәте | 87,94 | 91,46 | 95,12 |

______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 25 сентябрь, 744 нче карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына олимпия резервы училищесында белем алучылар туклануының спорт төренә һәм туклану продуктларының калориялелегенә бәйле булган тәүлеклек рационнан, энергия сарыф итү күләменнән чыгып билгеләнә торган көндезге рационы кыйммәте

| Күрсәткеч исеме | Спорт төрләре төркеме | Спорт төре | Энергочыгымнар, ккал* | Күрсәткеч зурлыгы, бер укучыга көненә сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Олимпия резервы училищесында белем алучы туклануының спорт төренә һәм туклану продуктларының калориялелегенә бәйле булган тәүлеклек рационнан, энергия сарыф итү күләменнән чыгып билгеләнә торган көндезге рационы кыйммәте | Кыска, әмма шактый зур физик йөкләнешләр белән бәйле спорт төрләре | Акробатика (спорт), бадминтон, таудан чаңгыда шуу, гимнастика (спорт, нәфис), атлы спорт, җиңел атлетика (барьер аша йөгерү, ыргыту, сикерү, спринт), җилкәнле спорт, синхрон йөзү, батутта сикерү, суга сикерү, чаңгыда трамплиннан сикерү, чаналы спорт, сноуборд, ату (җәядән ату, пуля белән, стендка ату), өстәл теннисы, фехтование, тимераякта фигуралы шуу, фристайл | 3 000 | 562 | 584 | 607 |
| | | | 3 500 | 596 | 620 | 645 |
| | | | 4 000 | 696 | 724 | 753 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | Спортның физик көч зур күләмдә һәм интенсив куелу белән тасвирлана торган төрләре | Бокс, көрәш (ирекле, грек-рим көрәше, дзюдо, самбо), волейбол, пляж волейболы, су полосы, гандбол, ишкәкле слалом, җиңел атлетика (400, 1500, 3000 метрга йөгерү), спорт уеннары (баскетбол, волейбол), софтбол, авыр атлетика, футбол, чирәмдәге хоккей, туплы хоккей | 4 000 | 654 | 680 | 707 |
| | | | 5 000 | 794 | 826 | 859 |
| | | | 5 500 | 849 | 883 | 918 |
| | Спортның озак вакытлы һәм киеренке физик көч куюга бәйле булган төрләре | ишү (академик, байдаркаларда һәм каноэда), биатлон, шосседа велосипедта узышу, тимераякта узышу спорты (күптөрле ярыш), чаңгыда ике төрле ярыш, чаңгыда узышу, йөзү, заманча биштөр ярыш, триатлон | 5 000 | 794 | 826 | 859 |
| | | | 5 500 | 849 | 883 | 918 |
| | | | 6 000 | 1 056 | 1 098 | 1 142 |
| *Тәүлеклек туклану рационының калориялелеге күләме олимпия резервы училищесының медицина персоналы тарафыннан укучының өйрәнүләр-күнегүләр үткәрүгә көч кую циклына бәйле рәвештә билгеләнә | | | | | | |